КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 853

2022 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2022 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны (карарга теркәлә);

2022 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан бер балага 51,9 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 ел, 7 сентябрь, 800 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 9 сентябрь, 853 нче
карары белән расланды

2022 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр
ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Т/с | Балалар һәм яшьләр ялын оештыру формасы | Норматив чыгымнар, бер көнгә бер кешегә койка-урынга сум |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр яны ял лагерындагы смена | 876,05 |
| 2. | Шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 865,35 |
| 3. | Палатка тибындагы лагерьдагы смена | 1056,82 |
| 4. | Белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагердагы, хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 187,30 |
| «5. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 170,08 |
| 6. | Шифаханә-курорт оешмаларындагы смена | 1325,56 |
| 7. | Кара диңгез яры буендагы шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 1720,62 |

___________________________________